ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

15.11.2023

г. Казань

**КАРАР**

№ 374-23/кс-2023

2024-2028 елларга «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 15.11.2023 № 48-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга 1 нче кушымта буенча Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Казан» халыкара аэропорты» АҖ) акционерлык җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2024-2028 елларга салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «Казан» халыкара аэропорты» АҖ өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны агызуга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан» халыкара аэропорты» АҖ ирекле файдаланылырга тиешле

мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2023 № 374-23/кс-2023
карарына 1 кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан» халыкара аэропорты» АҖ өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2024-2028 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Лаеш муниципаль районы | | | |
| 1 | «Казан» халыкара аэропорты» АҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 26,07 | 61,49 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 34,00 | 91,37 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 30,91 | 77,75 |
| | | 01.07.25 башлап 31.12.2025 кадәр | 30,91 | 77,75 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 30,91 | 77,75 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 32,65 | 79,59 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 32,65 | 79,59 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 32,75 | 79,67 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 32,75 | 79,67 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 34,61 | 81,79 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2023 № 374-23/кс-2023
карарына 2 кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Казан» халыкара аэропорты» АҖ өчен 2024-2028 елларга эчә торган суга һәм ташландык су агызуга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| Т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны хәл итүче оешма исеме, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Казан» халыкара аэропорты» АҖ | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2024 | 4 611,41 | х | - | 2,5 | 0,43 |
| | | 2025 | х | 1 | - | 2,5 | 0,43 |
| | | 2026 | х | 1 | - | 2,5 | 0,43 |
| | | 2027 | х | 1 | - | 2,5 | 0,43 |
| | | 2028 | х | 1 | - | 2,5 | 0,43 |
| 1.2 | Ташландык су агызу | 2024 | 2 971,63 | х | - | х | 2,66 |
| | | 2025 | х | 1 | - | х | 2,66 |
| | | 2026 | х | 1 | - | х | 2,66 |
| | | 2027 | х | 1 | - | х | 2,66 |
| | | 2028 | х | 1 | - | х | 2,66 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге